КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 13 сентябрь г.Казань № 830

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 – 2022 елларга «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» дәүләт программасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 30 октябрь, 823 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 4 июль, 549 нчы; 2019 ел, 29 март, 239 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2018 – 2022 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе стратегик үсешенең «Торак-коммуналь хуҗалык һәм шәһәр мохите» дигән төп юнәлеше кысаларында Татарстан Республикасында «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» өстенлекле проектын, 2019 елдан «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проектының «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» федераль проектын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 нче пунктта «2018 – 2022 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган 2018 – 2022 елларга «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

Программа исемендә «2018 – 2022 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

Программа паспортында:

«Дәүләт программасы исеме» юлында «2018 – 2022 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Программаның максаты» юлында «сыйфатын» сүзеннән соң «һәм уңайлылыгын» сүзләрен өстәргә;

«Программаның бурычлары», «Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары», «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме» һәм «Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td>«Программаның бурычлары</td><td>Шәһәр мохитенең уңайлылыгын кардиналь яхшырту, шәһәр мохите сыйфаты индексын 30 процентка арттыру, бу индекс нигезендә уңайсыз мохитле шәһәрләр санын ике тапкырга киметү;<br>гражданнарның уңайлы шәһәр мохитен формалаштыруда турыдан-туры катнашу механизмын булдыру, шәһәр мохитен үстерү мәсьәләләрен хәл итүдә катнашучы гражданнарның өлешен 30 процентка кадәр арттыру;<br>муниципаль берәмлекләр территорияләрен төзекләндерү чараларын бердәм таләпләр нигезендә үткәрүне тәэмин итү</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары</td><td>2018 – 2024 еллар.<br>I этап: 2018 ел;<br>II этап: 2019 – 2024 еллар;</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме</td><td>Программаны финанслауның гомуми күләме 17 162 596,9 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><td rowspan="2">Ел</td><td rowspan="2">Барлыгы*</td><td colspan="2">Шул исәптән түбәндәгеләр акчасы *</td></tr>
<tr><td>Татарстан Республикасы бюджет</td><td>җәлеп ителергә планлаштырылган федераль бюджет</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>2 669 608,9</td><td>2 014 500,0</td><td>655 108,9</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>4 492 988,0</td><td>2 254 736,3</td><td>2 238 251,7</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>2 000 000,0</td><td>2 000 000,0</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>2 000 000,0</td><td>2 000 000,0</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>2 000 000,0</td><td>2 000 000,0</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>2 000 000,0</td><td>2 000 000,0</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>2 000 000,0</td><td>2 000 000,0</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>17 162 596,9</td><td>14 269 236,3</td><td>2 893 360,6</td></tr>
</table>
* Чараларны финанслау күләмнәре тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары арасында субсидияләр бүлү нәтиҗәләре буенча һәм</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | муниципаль берәмлекләрне – Кече шәһәрләрдә һәм тарихый җирлекләрдә уңайлы шәһәр мохитен булдыруның иң яхшы проектлары буенча бөтенроссия конкурсында җиңүчеләрне бүләкләү өчен ел саен тәгаенләнергә тиеш |
| Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа чараларын үтәү Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләрендә комплекслы төзекләндерү проектларын тормышка ашырырга һәм иҗтимагый киңлекнең төзекләндерелгән территорияләре санын түбәндәге күләмдә арттырырга мөмкинлек бирәчәк:<br>2018 ел йомгаклары буенча 58 берәмлеккә;<br>2024 ел нәтиҗәләре буенча (2019 елдан туплана бара торган йомгак белән) 257 берәмлеккә.<br>Моннан тыш, 2024 ел ахырына программа чараларын тормышка ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>шәһәр мохите сыйфаты индексын 30 процентка арттыруга;<br>шәһәр мохите мәсьәләләрен хәл итүдә катнашучы гражданнарның өлешен 30 процентка кадәр арттыруга;<br>Татарстан Республикасының бер кешесенә туры килә торган төзекләндерелгән иҗтимагый территорияләр мәйданын 3,4 кв.метрга кадәр арттыруга.<br>Программа чаралары түбәндәгеләргә ярдәм итәчәк:<br>Татарстан Республикасы торак пунктларының экологик торышын һәм тышкы күренешен яхшыртуга, халыкның уңайлы яшәү һәм тормыш эшчәнлеге мохитен булдыруга, бу исә, үз чиратында, республикада демографик хәлнең яхшыруына турыдан-туры йогынты ясаячак, җәмгыятьтәге социаль киеренкелекне киметәчәк, торак пунктларның алга таба үсешенә, республика халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм икътисадый үсеш факторы буларак хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга көчле этәргеч бирәчәк»; |

Программаның 1 бүлегендәге икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны эшләү өчен нигезләр: «Россия Федерациясе стратегик үсешенең «Торак-коммуналь хуҗалык һәм шәһәр мохите» дигән төп юнәлеше кысаларында Татарстан Республикасында «Уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» өстенлекле проекты (алга таба – Өстенлекле проект), 2019 елдан – «Торак һәм шәһәр

мохите» илкүләм проектының «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» федераль проекты (алга таба – Федераль проект).»;

Программаның 2 һәм 3 бүлекләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Программаның төп максатлары һәм бурычлары, программа чаралары,
көтелә торган соңгы нәтиҗәләре тасвирламасы,
аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Программаның максаты булып Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр мохитенең сыйфатын һәм уңайлылыгын яхшырту тора.

Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

шәһәр мохитенең уңайлылыгын кардиналь яхшырту, шәһәр мохите сыйфаты индексын 30 процентка арттыру, әлеге индекс нигезендә уңайсыз мохитле шәһәрләр санын ике тапкырга киметү;

гражданнарның уңайлы шәһәр тирәлеген формалаштыруда турыдан-туры катнашу механизмын булдыру, шәһәр мохитен үстерү мәсьәләләрен хәл итүдә катнашучы гражданнарның өлешен 30 процентка кадәр арттыру;

муниципаль берәмлекләр территорияләрен төзекләндерү чараларын бердәм таләпләр нигезендә үткәрүне тәэмин итү.

Программаның максатларына ирешү һәм бурычларын үтәү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең иҗтимагый территорияләрен төзекләндерү чаралары тормышка ашырыла.

2018 елда эшләр Өстенлекле проект кысаларында башкарылды.

Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен үстерүнең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы белән шәһәр мохитенең уңайлылыгын кардиналь яхшыртуны тәэмин итү бурычы куелды, аны хәл итү максатларында, «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проекты составында тупланган тәҗрибәне исәпкә алып, Өстенлекле проектка алмашка килгән «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» федераль проекты расланды.

Федераль проект белән Кече шәһәрләрдә һәм тарихый җирлекләрдә – Уңайлы шәһәр мохитен булдыруның иң яхшы проектлары буенча бөтенроссия конкурсында җиңүчеләрдә уңайлы шәһәр мохитен булдыру проектларын тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектларына финанслашу шартларында субсидияләр бирү, шулай ук башка бюджетара трансфертлар бирү күздә тотыла.

Федераль проект чаралары түбәндәгеләр:

муниципаль берәмлекләрнең комплекслы төзекләндерү проектларын тормышка ашыру;

Уңайлы шәһәр мохитен булдыруның иң яхшы проектлары буенча бөтенроссия конкурсында җиңүчеләр проектларын кече шәһәрләрдә һәм тарихый җирлекләрдә тормышка ашыру;

башка илкүләм һәм федераль проектлар чаралары белән төзекләндерү буенча башкарыла торган чараларны синхронизацияләү;

шәһәр мохитенең сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чараларны өстенлекле финанслау башка илкүләм һәм федераль проектлар чаралары белән берлектә гамәлгә ашырылачак шәһәрләр исемлеген төзү;

уңайлы шәһәр мохитен булдыруның билгеле бер проектлары турында фикер алышу;

яшәү территориясендә уңайлы шәһәр мохитен булдыру проектлары тормышка ашырыла торган гражданнарның рейтинг буенча тавыш бирүләрен үткәрү (аның барышында яшәүчеләр төзекләндерү өчен өстенлекле объектларны билгели).

Моннан тыш, Федераль проект кысаларында «Акыллы шәһәр» шәһәр хуҗалыгын цифрлаштыру чараларын үтәү планлаштырыла.

Программаның максатларына ирешү һәм бурычларын үтәү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең иҗтимагый территорияләрен төзекләндерү чаралары ел саен өстәмә рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты хисабына тормышка ашырыла.

Муниципаль берәмлекләрнең комплекслы төзекләндерү проектларын тормышка ашыру чаралары үз эченә шул исәптән индивидуаль торак йортларны һәм аларны урнаштыру өчен бирелгән җир кишәрлекләрен төзекләндерү дәрәҗәсен инвентарьләштерү чараларын; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карары белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү» дәүләт программасы кысаларында җәмәгать территорияләрен, ишегалды территорияләрен, шулай ук хосусый милектә һәм алар янәшәсендә булган территорияләрдәге объектларны булдыру һәм үстерү чараларын ала.

Бу Программа максатларында иҗтимагый территория дип тиешле функциональ билгеләнештәге территория (мәйданнар, яр буйлары, урамнар, җәяүлеләр зоналары, скверлар, парклар, башка территорияләр) аңлашыла.

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре территорияләрен төзекләндерү эшләрен үткәрү инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен биналардан, корылмалардан һәм җәмәгать территорияләреннән физик, пространстволы һәм мәгълүмати файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү кирәклеген исәпкә алып башкарылырга тиеш.

Программа 2018 – 2024 елларда тормышка ашырылачак.

Ике этап күздә тотыла:

I этап: 2018 ел;

II этап: 2019 – 2024 еллар.

Программа чараларын үтәү комплекслы төзекләндерү проектларын Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләрендә тормышка ашырырга һәм иҗтимагый киңлекнең төзекләндерелгән территорияләре санын түбәндәге күләмдә арттырырга мөмкинлек бирәчәк:

I этап йомгаклары буенча 58 берәмлеккә;

II этап йомгаклары буенча (2019 елдан тупланып бара торган йомгак белән) 257 берәмлеккә.

Моннан тыш, 2024 ел ахырына программа чараларын тормышка ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

шәһәр мохите сыйфаты индексын 30 процентка арттыруга;

шәһәр мохите мәсьәләләрен хәл итүдә катнашучы гражданнарның өлешен 30 процентка кадәр арттыруга;

төзекләндерелгән иҗтимагый территорияләрнең Татарстан Республикасының бер кешесенә туры килә торган мәйданын 3,4 кв.метрга кадәр арттыруга.

## 3. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 17 162 596,9 мең сум тәшкил итә, шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджет акчасы исәбеннән – 14 269 236,3 мең сум, җәлеп ителергә планлаштырылган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 2 893 360,6 мең сум.

(мең сум)

| Ел | Барлыгы* | Шул исәптән түбәндәгеләр акчасы * | |
|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | җәлеп ителергә планлаштырылган федераль бюджет |
| 2018 | 2 669 608,9 | 2 014 500,0 | 655 108,9 |
| 2019 | 4 492 988,0 | 2 254 736,3 | 2 238 251,7 |
| 2020 | 2 000 000,0 | 2 000 000,0 | - |
| 2021 | 2 000 000,0 | 2 000 000,0 | - |
| 2022 | 2 000 000,0 | 2 000 000,0 | - |
| 2023 | 2 000 000,0 | 2 000 000,0 | - |
| 2024 | 2 000 000,0 | 2 000 000,0 | - |
| Барысы бергә | 17 162 596,9 | 14 269 236,3 | 2 893 360,6 |

*Чараларны финанслау күләмнәре тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары арасында субсидияләр бүлү нәтиҗәләре буенча һәм муниципаль берәмлекләрне – Кече шәһәрләрдә һәм тарихый җирлекләрдә уңайлы шәһәр мохитен булдыруның иң яхшы проектлары буенча бөтенроссия конкурсында җиңүчеләрне бүләкләү өчен ел саен тәгаенләнергә тиеш.»;

Программаның 4 бүлегендә:

бишенче абзацта «2018 – 2022 елларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

җиденче абзацка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәрә:

«Исемлеккә иҗтимагый фикер алышулар һәм рейтинг буенча тавыш бирү йомгаклары буенча ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

унынчы абзацта «2020» саннарын «2024» саннарына алыштырырга;

унберенче абзацта «2020» саннарын «2024» саннарына алыштырырга;

Программага теркәлгән 1 нче һәм 2 нче кушымталарны (карарга теркәләләр) яңа редакциядә бәян итә

ргә;

Программага теркәлгән 3 нче кушымтада:

нумерация башисемендә «2018 – 2022 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

исемендә «2020» саннарын «2024» саннарына алыштырырга;

Программага теркәлгән 4 нче кушымтада:

нумерация башисемендә «2018 – 2022 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 бүлектә:

1.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Бу Татарстан Республикасы территориясендә индивидуаль торак йортларны һәм аларны урнаштыру өчен бирелгән җир кишәрлекләрен төзекләндерү дәрәҗәсен инвентарьләштерүне үткәрү тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программаларына һәм заманча шәһәр мохитен формалаштыруның муниципаль программаларына ярдәм күрсәтү өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 9 нчы пунктындагы «и» пунктчасын үтәү йөзеннән эшләнде.»;

1.2 нче пунктта «2020» саннарын «2024» саннарына алыштырырга;

3 бүлектә:

3.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Индивидуаль торак йортларны һәм аларны урнаштыру өчен бирелгән җир кишәрлекләрен инвентарьләштерү Комиссия рәисе тарафыннан расланган график (алга таба – график) нигезендә үткәрелә.»;

3.4 нче пунктта «2020» саннарын «2024» саннарына алыштырырга;

Программага теркәлгән 5 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче; 2016 ел, 17 февраль, 101 нче; 2016 ел, 27 апрель, 252 нче; 2016 ел, 12 май, 298 нче; 2016 ел, 10 июнь, 396 нчы; 2016 ел, 12 октябрь, 740 нчы; 2016 ел, 26 декабрь, 989 нчы; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 13 май, 281 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 821 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 895 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1117 нче; 2018 ел, 11 июнь, 458 нче; 2018 ел, 16 ноябрь, 1002 нче; 2019 ел, 5 март, 156 нчы; 2019 ел, 26 апрель, 344 нче; 2019 ел, 27 июнь, 517 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә, 35 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «35. | Татарстан Республикасы территориясендә хәзерге заман шәһәр мохитен формалаштыру | Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр мохитенең сыйфатын һәм уңайлылыгын яхшырту;<br>Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруда кызыксынучы гражданнарны һәм оешмаларны җәлеп итүнең универсаль механизмнарын булдыру;<br>муниципаль берәмлекләр территорияләрен төзекләндерү чараларын бердәм таләпләр нигезендә үткәрүне тәэмин итү». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин